РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Тенишевского**
**городского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Тенеш**
**штп. җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул.Ленина, 8,пгт. Тенишево, 422839
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128, ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

Ленина урамы, 8,Тенеш штп, 422839,
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128, ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

# КАРАР

2020 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Тенеш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге өчен 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча , гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр

тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” 2019 елның 19 апрелендәге 9 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т. п., Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш. т. б., Пионер ур., 18 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. Е. Изотова

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты 2020 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча, гарантияле исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе*( сумнарда)*** |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3670,18 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын (останков)) зиратка илтү | 522,27 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты 2020 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча, гарантияле исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 188,35 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3481,83 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын (останков)) зиратка илтү | 522,27 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |